**Татарстан Республикасы**
**Нурлат муниципаль районы**
**Биккол авыл җирлеге советы**

# КАРАР

**№72** **“30” ноябрь 2018 ел**

**Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге советының 22.10. 2015 тә кабул иткән “ Физик затлар милкенә салым турында” гы №9 Карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 32 бүлеге һәм Россия Федерациясенең аерым законнары актлары нигезендә, Татарстан республикасы Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге Советы Карар кылды:

1. Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Советының 22.10.2015 дә кабул иткән “Физик затлар милкенә салым турында” гы № 9 Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 3 подпункты 4 нче абзацында “бер торак бина(торак йорт) сүзен “бер торак йорт” сүзе белән алыштырырга;

1.2.Карарны түбәндәге редакциядәге 2.1 пункты белән тулыландырырга:

2.1.Салым түләүдән азат итәргә:

2.1.1. 18 яшькә кадәрге биш яки аннан да артык балалары булган гражданнарны;

2.1.2. әлеге пунктның 2.1.1. подпунктында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы салым салу объектларының түбәндәге төрләренә кагыла:

1)фатирлар(бүлмәләр) яки торак йортларга;

2) Гараж яки машина урыннарына.

Салым ташламасы салым түләүче сайлавы буенча гаиләгә туры килгән һәр төр салым салу объектының берсенә бирелә. Салым ташламасы Биккол авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә үз милекләрендә булган һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым объектына куелган һәм түләнергә тиешле сумма күләмендә бирелә.

Салым ташламасына хокукы булган зат ташлама бирүгә гариза һәм салым ташламасына хокукы булуны раслаган документларны салым органына тапшыра.

Салым ташламасы бирү өчен сайланган салым салу объектлары турында уведомление салым органына салым түләүче тарафыннан күрсәтелгән объектларга салым ташламасы кулланыла башлана торган салым периоды саналган елның 1 ноябренә кадәр тапшырыла.”

2.Үз көчен югалткан дип санарга:

-Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советының “ “Физик затлар милкенә салым турында”гы 22.10. 2015 тәге № 9 Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 18 апрелендә Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советы кабул иткән № 57 Карарны;

- Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советының “ “Физик затлар милкенә салым турында”гы 22.10. 2015 тәге №9 Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 11 июлендә Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советы кабул иткән №63 Карарны;

- Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советының “ “Физик затлар милкенә салым турында”гы 22.10. 2015 тәге №9 Карарына үзгәрешләр кертү турында”гы 2018 елның 14 ноябрендә Нурлат муниципаль районы Биккол авыл җирлеге советы кабул иткән №71 Карарны;

3. Бу карар Россия Федерациясе Салым Кодексының 5 матдәсе нигезендә гамәлгә керә һәм 2018 елның 1 гыйнварендә килеп туган хокукый мөнәсәбәтләргә тарала.Ул бары тик 2019 елның 1 гыйнвареннән, әмма рәсми бастырылган көннән соң ким дигәндә бер ай үткәннән соң гына гамәлгә керәчәк 1.1 пунктка кагылмый.

4. Гамәлдәге Карарны Биккол авыл җирлегенең мәгълүматый стендларында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында, бастырырга .

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Биккол авыл җирлеге муниципаль
берәмлеге советы рәисе Р.Х. Әхмәтшина